# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.6 статьясына үзгәреш кертү һәм "Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 6 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 22 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.6 статьясындагы беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), Ватаным Татарстан, 2011, 9 август, 18 октябрь, 4 ноябрь, 23 ноябрь), "Пассажирлар йөртүне коммерциячел гамәлгә ашыру очракларыннан тыш," сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында" 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 6 өлешен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 6) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Пассажирлар йөртүне коммерциячел оештыруга әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән шартнамәләр алар гамәлдә булу срогы тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була дип танылалар.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 7-ТРЗ